**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СИМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ**
**III ЧАКЫРЫЛЫШ L УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 2**

Симәк авылы «30» гыйнвар 2019 ел

**Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Советы һәм Башкарма комитетының 2019 елга ниятләнелә торган төп чаралар планын раслау турында**

Симәк авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Садертдиновның чыгышын тыңлаганнан соң, Симәк авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Советы тарафыннан 2019 елга ниятләнгән төп чаралар планын расларга (1 нче кушымта).

2. Даими комиссияләргә 2019 елга Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Советы тарафыннан ниятләнгән төп чаралар планында каралган мәсьәләләрне вакытында әзерләүне тәэмин итәргә.

3. 2019 елга Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан ниятләнгән төп чаралар планын расларга (2 нче кушымта).

4. Әлеге карарның үтәлеше өчен җаваплылыкны Симәк авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Симәк авыл җирлеге Советы башлыгы:** **Р.Ә. Садертдинов**